**Бу мөһим!**



**Сулдан уңга:** Сәйфуллина Ралия, Рахматуллина Эльвина, Маннапова Гүзәл, Ильясова Элина.

# Үзләре сайлаган язмыш

## Кулларына диплом алган яшь белгечләр яхшы эшкә урнашып, зур тормышта үз урыннарын тапсын иде

**Бу көннәрдә белем бирү учреждениеләре укучылары белән хушлаша.**
**Икенче туган йортына әверелгән мәктәпне тәмамлаучылар аттестат алып, язмышын хәл итәсе һөнәрне сайлау алдында тора. Сайлаган белгечлекләре буенча дипломнарга ия булган кичәге студентлар яраткан альма-матеры белән хушлаша һәм чын, зур тормыш юлына баса. Һәм менә шушы агым еллар дәвамында килә, белем алуга омтылышлы яшьләр сафлары ташкындай зур.**

Дипломлы белгеч статусына ия булган меңләгән яшь белгечләр арасыннан шушы дүрт сөйкемле туташны сайлап алу очраклы түгел. Фотосурәттәге кызлар Уфа финанс-икътисад колледжын уңышлы тәмамлап, диплом алу бәхетенә ирешкән.

— Республиканың төрле тарафларыннан җыелган бу булдыклы кызлар уку елларында үзенчәлекле студент язмышын кичереп, чын ахирәтләр, җитди әзерлекле белгечләр булып җитеште, — ди туташлар турында кураторлары, колледжның инглиз теле укытучысы Рәйсә Абдуллина.

Шулай итеп, Уфа сылуы Элина Ильясова да тырышып уку нәтиҗәсе булган дипломын кулына алып сөенде. Инглиз телен яратып өйрәнүче, яхшы өлгерешле, актив позицияле туташ төркемнең профоргы да булган. Чибәр кызлар — Сәйфуллина Ралия белән Маннанова Гүзәл Чакмагыштан. Алар икесе дә сәнгатьле уку осталары. Кечкенәдән туган телне яратып өйрәнеп үсүләре монда да ярдәм иткән аларга. Уку йортында узган рухиятле кичәләрдә татар һәм башкорт әдипләренең әсәрләрен укып, иптәшләрендә дә матур әдәбиятка мәхәббәт уятуга ирешкәннәр.

Рәхмәтуллина Эльвина — Кызыл диплом иясе, Кырмыскалы кызы. Үзе җырчы. Иҗтимагый тормышта актив, сәләтле яшьләрнең берсе булган Эльвина да, ахирәтләре кебек үк, РФ Хөкүмәте каршындагы финанс университетының Уфа филиалында укуын дәвам итмәкче.

ВУЗ аббревиатурасын кызлар шаярып "выйти успешно замуж", дип аңлаталар икән, аптырыйсы юктыр. Яхшы тормыш юлдашы очрату иң җитди өлкә әле ул. Диплом — статус, белгечлек, икмәгең дигәнне аңлатса, ә менә гаилә?

(Ахыры 2нче биттә).

# Үзләре сайлаган язмыш




**(Башы 1 нче биттә).**

Моны яхшы аңлаган кызларыбыз башта төпле белемгә ия булып, аннан матур гаилә кору теләгендә иртәгәсе көнгә ышанып атлый, чөнки әле алар яшь, сылу, чәмле һәм максатчан, барысы да алар теләгәнчә матур булсын гына. Бу көннәрдә белем гранитын кимереп, борчу-мәшәкатьле уку елларын артта калдырып, диплом алуга ирешкән егет-кызларыбызның шатлыкларын уртаклашып, чын күңелдән котлыйбыз һәм үзләре сайлаган язмыш юлларында уңышларга ирешүләрен телибез. Тагы бер сынау баскычы артта калды. Якты булсын киләчәк!

Бу буын яшьләргә алмашка килергә әзерләнүчеләрнең дә беренче уңышлары турында мәгълүм булды. БР Мәгариф министры Әлфис Гаязов "Интерфакс" агентлыгына 2015 елда БДИның үтәкүренмәле һәм уңышлы узуын билдерде. Быел ул сынауны 22 мең яшь кеше үткән. Бөтен фәннәр буенча да уртача баллар арткан. 61 кеше 100 балл җыйган. Узган ел бу күрсәткеч 14 булган. Ике төп фәннән минималь балл җыя алмаганнарның саны соңрак билгеле булачак, дигән министр. Имтихан вакытында көтелмәгән хәлләр булмаган, тәртип бозучылар саны быел сигез очрак теркәлеп, республика буенча 1669 күзәтүче эшләгән.

**Алсу ТӨХВӘТУЛЛИНА.**

**Фәнил АБДУЛЛИН фотосы.**

**Материалларны Елена ФАТЫЙХОВА, Эльвира ӘСӘДУЛЛИНА, Руфина ХӘСӘНОВА әзерләде.**